Республика Татарстан
СОВЕТ
ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

Татарстан Республикасы
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЛӘКЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«02» нче ноябрь 2020 ел № 3

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Ләке авыл җирлегендә халык җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Уставының 18.1 ст., Сарман муниципаль районы " Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

Карар:

Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Ләке авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены 2020 елның 14нче ноябренә 10.00 сәгатькә билгеләнде.

1. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2021 елда Ләке авыл җирлеге Ләке авыл территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән дә килешәсезме?:

- Ләке авылы чишмәсен төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм төзелеш эшләре өчен түләү.
- Ләке авылына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру.
- Ләке авылы зират өчен чоку чүкече һәм генератор сатып алу ;
- Ләке авылында җирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту.
- Ләке авылында урамнарны яктырту буенча өстәмә ут ноктолар урнаштыру;

- МТЗ-82 махсус техника өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу;
- Ләке авылы территориясен һәм юл буйларын чабу.
- Ләке авыл җирлегендә өлкәннәр һәм инвалидлар көне үткәрү өчен бүләк пакетлары алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

2.Ләке авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында билгеләнгән срокта урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек башлыгы ____________ Л. И. Шәрипова